| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2024 г.Лениногорск № 91

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 1 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 1 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.1 пунктта:

а) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә, аны түләү бурычын үтәүдән күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителгән булса;»;

б) 3 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 5 һәм 6 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) җәзага хөкем ителгәннәргә карата штраф яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә амнистия яки ярлыкау турындагы актлар куллану, шуның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә;

б) «Башкару эшчәнлеге турында»2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр күләме бурычлыга карата банкротлык турындагы эш кузгату өчен банкротлык (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт узган булса, башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгару;»;

г) түбәндәге эчтәлекле 6.1 пунктча белән тулыландыырырга:

«6.1) банкрот турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителү;»;

2) 3.1 пунктта:

а) «в» пунктчасында «хисаплылыктан өземтә» сүзләрен «белешмә» сүзенә алмаштырырга»;

б) «г» пунктчасында «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган» сүзләрен өстәргә»;

в) «д» пунктчаның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«амнистия турында акт яки штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;»;

г) «д» пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.».

2. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс, икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы
урынбасары С.В.Тимаков